СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**29.10.2018**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 329**

.
Зеленодольск муниципаль районы Советының 2013 елның 14 ноябрендәге 324 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында
.

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2013 елның 14 ноябрендәге 324 номерлы карары белән расланган, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында «Зеленодольск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» муниципаль учреждениесе җитәкчесе О.П. Дёгтева мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Бюджет кодексында, бюджет процессын камилләштерү өлешендә, үзгәрешләр кертелүгә бәйле рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1.Зеленодольск муниципаль районы Советының 2013 елның 14 ноябрендәге 324 номерлы карары белән расланган Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1) 9 статьяның 5 пункты. «Бюджет процессында катнашучыларның бюджет вәкаләтләре» сүзләреннән соң түбәндәге эчтәлекле унсигезенче абзац өстәргә:

«федераль закон нигезендә гавами-хокукый берәмлек мәнфәгатьләрен Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә район бюджеты акчаларын баш бүлүченең вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы орган тәкъдим итә торган муниципаль берәмлеккә карата башка дәгъвалар буенча.»;

2) түбәндәге эчтәлекле 24.1 статья өстәргә:

«24.1 статья. Озак сроклы бюджет планлаштыруы

1.Озак сроклы бюджет планлаштыруы, әгәр район Советы аны Россия Федерациясе Бюджет кодексы таләпләре нигезендә төзү турында карар кабул итсә, районның озак сроклы чорга бюджет фаразын формалаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2. Озак сроклы чорга район бюджет фаразы дигәндә район бюджетының (районның берләштерелгән бюджетының) төп характеристикалары фаразын үз эченә алган документ, гамәлдә булган чорда муниципаль программаларны финанс белән тәэмин итү күрсәткечләре, район бюджетын (районның берләштерелгән бюджетын) характерлаучы башка күрсәткечләр, шулай ук озак сроклы чорга бюджет сәясәтен формалаштыруның төп алымнарын үз эченә алган документ аңлашыла.

3.Озак сроклы чорга районның бюджет фаразы районның социаль-икътисадый үсеше фаразы нигезендә һәр өч ел саен алты елга һәм аннан да күбрәк елга әзерләнә.

Районның озак сроклы чорга бюджет фаразы, тиешле чорга районның социаль-икътисадый үсеш фаразының һәм район бюджетының аның гамәлдә булу чорын озайтмыйча, кабул ителгән карарының үзгәрүен исәпкә алып, үзгәртелергә мөмкин.

4. Озак сроклы чорга районның бюджет фаразын эшләү һәм раслау тәртибе, шулай ук составына һәм эчтәлегенә карата таләпләр, Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм әлеге Нигезләмә таләпләрен үтәп, район Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.

5. Озак сроклы чорга (муниципаль программаларны финанс белән тәэмин итү күрсәткечләреннән тыш) районның бюджет фаразы проекты (бюджет фаразына үзгәрешләр проекты) район бюджеты турындагы карар проекты белән бер үк вакытта район Советына тапшырыла.

6. Районның бюджет фаразы (бюджет фаразын үзгәртү) озак сроклы чорга район Башкарма комитеты тарафыннан район бюджеты турында карар рәсми басылып чыккан көннән алып ике айдан артмаган срокта раслана (раслана).»;

3) 25 статьяның 2 пункты. «Район бюджеты проектын төзү өчен кирәкле белешмәләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Район бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә таләпләр) билгели торган Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Россия Федерациясе Президенты юлламасы нигезләмәләренә;

Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы Дәүләт Советына юлламасына;

районның бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре һәм районның салым сәясәтенең төп юнәлешләренә;

районның социаль-икътисадый үсешен фаразлавына;

озак сроклы чорга районның бюджет фаразына (бюджет фаразы проектына, бюджет фаразына үзгәрешләр кертү проектына);

муниципаль программаларына (муниципаль программалар проектларына, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр проектлары).»

4) 26 статья. «Районның социаль-икътисадый үсеше фаразын» түбәндәге эчтәлекле 7 пункт белән тулыландырырга:

«7. Озак сроклы чорга районның бюджет фаразын формалаштыру максатларында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 170.1 статьясы һәм әлеге Нигезләмәнең 24.1 статьясы нигезендә, район Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә озак вакытлы чорга районның социаль-икътисадый үсеше фаразы эшләнә.»;

5) 33 статья. «Район бюджеты проекты белән бергә төзелә торган документлар һәм материаллар» түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Районның чираттагы финанс елына һәм план чорына бюджеты турындагы карар проекты белән бер үк вакытта район Советына түбәндәгеләр тапшырыла:

Чираттагы финанс елына һәм план чорына районның бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

агымдагы финанс елының узган чорында районның социаль-икътисади үсешенең якынча нәтиҗәләре һәм агымдагы финанс елында районның социаль-икътисади үсешенең көтелгән нәтиҗәләре;

районның чираттагы финанс елына һәм план чорына социаль-икътисадый үсеш фаразы;

чираттагы финанс елына һәм план чорына районның берләштерелгән бюджетының төп характеристикаларын фаразы (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет дефициты);

район бюджеты проектына аңлатма язуы;

бюджетара трансфертларны бүлү методикалары (методикалар проектлары) һәм исәп-хисап;

Чираттагы финанс елы һәм план чорының һәр елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына муниципаль бурычның иң югары чиге;

агымдагы финанс елына район бюджетының көтелгән үтәлешен бәяләү;

район Советы, Контроль-хисап палатасы тарафыннан тәкъдим ителгән күрсәтелгән органнарның бюджет сметалары проектлары, күрсәтелгән бюджет сметаларына карата финанс-бюджет палатасы белән каршылыклар барлыкка килгән очракта, тапшырыла;

озак сроклы чорга районның бюджет фаразын (бюджет фаразы проекты, бюджет фаразына үзгәрешләр проекты);

район бюджеты керемнәре чыганаклары реестры;

башка документлар һәм материаллар.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәгеТатарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль**
**районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.В.Тыгин**